КАДИРОВА Э.Х. (КФУ)

# XVI ГАСЫР ИСТӘЛЕГЕ – КОРЪӘН ТӘФСИРЕ ХАКЫНДА

Татар әдәби теле тарихында XV-XVI гасырлар әһәмиятле урын алып тора, чөнки, белгәнебезчә, бу чор галимнәр тарафыннан региональ төрки телләрнең формалашу вакыты дип билгеләнә [Татар. грамматика,1993:34; Хаков,2003:71].

Бәхәссез, бу дәвернең тел ситуациясен, тел процессларын билгеләү өчен, төрле жанрдагы язма истәлекләрне өйрәнү кирәк. Бу чорда төрле территорияләрдә, мәсәлән, Казан, Кырым, Касыйм һәм Себер ханлыкларында язылган, яки иске османлы теле ядкярләрен, аларның тел үзенчәлекләрен тикшерү шулай ук нәтиҗәләрне ныгытырга мөмкинлек бирә. Фәндә XV-XVI гасыр истәлекләреннән Мөхәммәдьяр әсәрләре, Өмми Камал, Колшәриф иҗатлары, “Җәмигъ эт-тәварих” хезмәте, ярлыклар һ.б. ядкярләр белән беррәттән, Коръән тәфсире дә искә алына. Ул 1958 елда Казанда табыла һәм хәзерге вакытта Казан дәүләт музее фондында саклана.

Коръән тәфсире һиҗри белән 913, ә милади белән 1507 нче елда язылган. Кулъязма яхшы сакланган, барлыгы 856 бит тәшкил итә.

Истәлек турында фәндә бик аз искә алына. “Борынгы татар әдәбияты” хезмәте авторлары бу китапны “экономик  һәм культура мөнәсәбәтләре нигезендә көнчыгыш һәм Урта Азия халыкларыннан кергән, укымышлылар арасында кулдан кулга күчерелеп таралган  төрле эчтәлектәге әсәрләр” исемлегенә кертәләр һәм “татарның борынгы төрки телендә язылган булуы белән әһәмиятле” дип ассызыклыйлар [БТӘ:340-341]. Галим Җ.Зәйнуллинның аерым хезмәтләрендә дә бу кулъязма искә алына [] , аның докторлык диссертациясе докладында да ул турыда мәгълүмат китерелә [Зайнуллин,1999:30].

Коръән тәфсиренең авторы хезмәтенең язылу сәбәбен күрсәтүне кирәк дип таба. “Белгел, әй ғәзиз қәрдәш. Бу китаб шәриф вә дөррилатиф җәмғ идүб тәрҗемә қылма нә сәбәб” дип сорау бирә һәм моңа кадәр булган

галимнәр Хак тәгалә сүзләре диңгезен һәм андагы энҗе бөртекләрен гарәп телендә нәшер иткәнлектән, барлык теләгәннәр дә аннан файдалана алмый, ә Аллаһның бу колы гомум файда булсынга, аны төрки телгә тәрҗемә итә дип җавабын да ача, барлык якын кешеләр, олысы-кечесе, бу энҗе бөртекләре белән таныша алачаклар дип сөенә. Бу турында автор истәлекнең сигезенче битендә аңлатма бирә.

Кулъязманың эчтәлегенә килсәк, бу юллардан соң ук Коръәннең йәсин сүрәсеннән аятьләр китерелә һәм аларга аңлатма бирелә. Мәсәлән, кулъзманың 20-21 нче битләрендә

**وَجَاء مِنْ أَقْصَى الْمَدِينَةِ رَجُلٌ يَسْعَى قَالَ يَا قَوْمِ اتَّبِعُوا الْمُرْسَلِينَ اتَّبِعُوا مَن لاَّ يَسْأَلُكُمْ أَجْرًا وَهُم مُّهْتَدُونَ**

аяте китерелә һәм аңа аңлатма бирелә: [ йәгни шәһәрүң уртасындан бер кеше тиз-тиз кәлүб дидекем йә қәwүм мөтәбәғәт идүң, ошбу рәсүлләрә кем боларуң дегүлләре хакдур, дүнүбул кеше бу рәсүлләрә сурдыкем һич ишбу динә диғwәт қылдығуңуз ичүн болардан хақ эстәрмесез. Анлар диделәр кем безүм аллаһ қатындадур. Болардан әҗер эстәмәwүз. Бәс дүнүб ул кеше ул қәwүмә кирү чагырдыкем йә қәwүм мөтәбәғәт қылуб шул кемсәләрә кем сездән ахыр хақ эстәмәзләр, болар һидәйәт булмыш қәwүмләрдүр бу кәлүб чағыран кеше димешләр кем ул рәсүлләр догасилә кирү дерелде. Ул ислама кәлде. Бәгзеләр диделәр кем сайрады диде Анларуң доғасилә шифа булды, чөн ул хәбиб ишетде кем ул қәwүм ул рәсулләре улдур. Мәңа қәсд итделәр, сәғый идүб кәлде кем, анлары мәнғ идә үлдүрмәгә кумайа, чөн ул қәwүм ул хәбибүң ул сүзләрүн ишетделәр, белделәр кем. Кем ул дәхи анларуң диненә мөтәбәсәт қылмыш диделәр. Аңа кем йә хәбиб йәгни сәндә безүм динүмүз варуб анларуң диненәме кердүң Хәбиб дәхи җаwаб вирде шөйлә хақ тәғәлә бойурды ].

Аятьләрнең гарәпчәсе кызыл кара белән язылган, кайбер очракларда хәрәкәләр кара кара белән куелган. Яңа сүрә башланганда “Бисмиллаһ” дигән сүздә һәр очракта س ( син) хәрефе бер юл озынлыгында сузылып бирелә, ә бу – сүрәләрне табуны җиңеләйтә.

Кулъязмада төзәтмәләр юк диярлек, текст бик пөхтә язылган һәм бер генә кеше почеркы икәнлеге сизелә. Шулай да берничә бозылган урын бар. Мәсәлән, 41 нче бит яртылаш язылгач сызып ташланылган һәм текст яңа биттән башлана, әмма бозылган битне ташламаганнар. Кайбер битләрдә башка почерклар белән язылган язмалар күзәтелә. 3  нче биттә “Ибраһим углы бине Гыйльметдин торыр” дип ике урынга язылган.  Андый язмаларны төрле вакытларда әлеге кулъязманың хуҗалары булганнардыр дип уйлыйбыз. Бит кырыйларында башка эчтәлекле юллар да бар.  Мәсәлән, 48 нче биттә “Шиһаб дийү логатьдә һәд ак нәснәйә дирләр ки нурлу ла, ягъни шиһаб – нуры ак нәрсә һәм ялтыраучы” дип язылган.

Тәфсирдә Йәсин сүрәсеннән Нәс сүрәсенә кадәр аңлатма бирелә. Шул рәвешле, кулъязманы ике кисәктән торган хезмәтнең икенче кисәге дип уйларга мөмкинлек туа.

Аятьләргә аңлатмалар бик җентекле, төгәл, аерым вакыйгалар белән тулыландырылган. Мәсәлән, тәфсирдә Йәсин сүрәсенә аңлатма 6 – 44 битләрдә бирелә, ә аннан соң килгәне (“Әссафат” сүрәсе) 44 – 86 битләрне ала. Шактый калын саналган Фәрит Сәлмән тәфсирендә Йәсин сүрәсе – 6, алдагысы 7 бит күләмендә [Коръән Китабы, 2003:410-416].

Кәүсәр сүрәсен автор түбәндәгечә аңлата: йәғни Хак тәгалә бойурды кем йә Мөхәммәд без сәңа хәйр кәүсәр вирдүк, Коръән кеби вә гыйлм кеби мукатил айрур морад бондан бер ырмакдур, җәннәт эчендә, балчыгы мискдүр вә комы кабуры инҗүдүр, аклыгы кардан акдур, ләззәте балдан татлудур, ике кәнәре алтундандур, йумшаклыгы сүд күбүгендән йумшакдур, кәдәхләре кәнәрендә көмешдән күкдәге йылдызлар сагышынча Бер эчем андан айрук сусамаз әввәл андан эчәнләр, мөһәҗирләрүң фәкыйрьләре ула ки, тунлары керлү, сачлары тузгук. Баглы капулары анлара ачмазлар вә көрклү, нигъмәтлү гаүрәтләре анларә .. , дөнйада бер хәҗәтләре йиренә кәлмәз ул арзу узәренә улурлар, әмма мәртәбәләре Аллаһ катында айлардур кем әгәр бере анд эчүб дисә ки ишбу нәснә фәлән вакытда улысардур дийү, Хак тәгалә аны йалан кылмамышичүн кәрәк ки ул дидеген йиренә кәтүрә вә дәхи

бойурды ки .... йәғни биш вакыт намаз Аллаһ ризасы ичүн йә Мөхәммәд дәхи ижтиһад кыл тәгать эчендә күксеге кыйблайа тәвәжҗүһ итдүр вә дәхи бәйрәм көн бәйрәм намазы кылуб корбануңы нахранилә вә әлүге дога вакытында күксүңә бәрәбәр күтүр вә дәхи бойурды ки ... йәғни ул ....сәне дошман тотуб тәгын идәрдер ки, бу Мөхәммәд абтардур, соңында калачак кемсәсе йукдур ки аны андурасән, аңа мәлүл улмагыл ки абтар улдур, улдундан соңра аңылысар дәгүлсән ход кыйәмәтә дәкен бәнүмилә аңылысарсын һәр мәкәндә оныдылысар дәгүлсен, ул көлле әһлилә малилә вә әүләдилә катыг улысар кересәр ки асла нәселе калачак дәгүл.

Күренә ки, истәлек эчтәлеге ягыннан да, теле юнәлешендә дә галимнәрнең күз уңында булырга лаек.

## ӘДӘБИЯТ


1. БТӘ - Борынгы татар әдәбияты. - Казан: Тат.кит.нәшр, 1963. – 580 б.
2. Зайнуллин Г.Г. Татарская богословская литература XV-XVI
3. Коръән Китабы (Коръән-Кәрим аятьләренең мәгънәләренә татарча сүзгә-сүз аңлатмалар һәм гарәпчә яңгырашын хәзерге татар хәрефләренә нигезләнеп бирүче Фәрид хәзрәт Хәйдәр Сәлман). – Казан: “Раннур” нәшр., 2003. – 1200 б.
4. Татарская грамматика: В 3-х т. – Т. 1. – Казань: Тат. кн. изд-во, 1993. – 584 с.
5. Хаков В.Х. Тел - тарих көзгесе / В.Х.Хаков. – Казан: Тат. кит. нәшр., 2003. – 295 б.